РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«13» декабрь 2024 ел Олы Кайбыч ав. № 297

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге муниципаль милкеннән федераль милеккә тапшырыла торган күчемсез милек исемлеген раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Милекне федераль милектән Россия Федерациясе субъекты милкенә яисә муниципаль милеккә, Россия Федерациясе субъекты милкеннән федераль милеккә яисә муниципаль милеккә, муниципаль милектән федераль милеккә яисә Россия Федерациясе субъекты федераль милкенә тапшыру турында карар кабул итү өчен кирәкле документлар исемлеге турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 13 июнендәге 374 номерлы карарына, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Уставына таянып, «Автодор» дәүләт компаниясе мөрәҗәгате нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы муниципаль милкеннән «Сәнәгать, энергетика, транспорт, элемтә, радиотапшырулар, телевидение, мәгълүмат җирләре, космик эшчәнлекне тәэмин итү өчен җирләр, оборона, иминлек җирләре һәм башка махсус билгеләнештәге җирләр» категориясеннән булган 16:21:010608:249 кадастр номерлы Татарстан Республикасы, Кайбыч муниципаль районы, Олы Кайбыч авыл җирлеге адресы буенча урнашкан « Көнчыгыш» М-12 федераль юлының бүленгән полосасын төзи торган җир кишәрлекләрен түләүсез федераль милеккә тапшырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасында һәм Ульяновск өлкәсендә дәүләт мөлкәте белән идарә итү буенча федераль агентлыкның регионара территориаль идарәсенә җибәрергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Совет Рәисе,
Кайбыч муниципаль
Районы Башлыгы А.И.Рәхмәтуллин